КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2022 ел, 7 декабрь | г.Казань | № 1300

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карары белән расланган 2022 елда сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карары белән расланган 2022 елда сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «(алга таба - бюджет яки бюджет язмасы турындагы закон)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эш бирүчеләр экстремистик эшчәнлеккә яисә террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә, йә аларга карата массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булырга тиеш түгел.»;

10 пунктта:

икенче абзацта «, һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан эш бирүче тарафыннан субсидия бирү, файдалану шартлары, максатлары, тәртибе, шулай ук электрон почта адресы үтәлешен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга» сүзләрен төшереп калдырырга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүченең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый икәнен раслый торган белешмә.»;

18 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән субсидия бирүнең планлаштырылган нәтиҗәсен тәгәлләүнең төгәл датасы һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең ахыргы мәгънәсе (нәтиҗәләрнең конкрет микъдари характеристикасы);»;

ундүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидия алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирелгәндә);»;

19 пунктның җиденче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Субсидия бирүнең планлаштырылган нәтиҗәләре:

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия биргәндә - укытуны тәмамлаган хезмәткәрләр саны, гаризада күрсәтелгән хезмәткәрләр санының кимендә

95 проценты һәм укуны тәмамлаган хезмәткәрләр арасыннан уку тәмамланганнан соң өч ай узгач, мәшгуль булучылар өлеше кимендә 85 проценты;

чыгымнарны каплауга субсидия бирелгәндә - укытуны тәмамлаган хезмәткәрләр арасыннан укуны тәмамлаганнан соң кимендә 85 процент узгач, мәшгуль булучылар өлеше.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

24 пунктта «максатларын,» сүзен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин